| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«УРДАЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ТУКТАР-УРДАЛАСЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 2021 елның 24 ноябре | №30 |

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 2 октябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2020 елның 9 ноябрендәге 370-ФЗ Федераль закон һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 26.13 статьясы нигезендә, Лениногорск шәһәре прокуратурасының 2021 елның 18 ноябрендәге 02-08-03 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 2 октябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.7 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Татарстан Республикасы Законы нигезендә авыл җирлеге, шәһәр эчендәге район, федераль әһәмияттәге шәһәр эчендәге территория, муниципаль округ, шәһәр округы территорияләренең торак пункты өлешендә яисә муниципаль район чикләрендәге җирлекара территориядә урнашкан торак пунктның өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Туктар-Урдаласы авылы, Совет ур., 98 адресы буенча урнашкан административ бинада, Совет ур., 103 йорт, Карагай авылы, Тельман ур., 31 йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Туктар-Урдаласы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Г.Ә.Әхмәтова